**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422610 г.Лаишево,**
**ул. Первомайская, д.39**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

**422610 Лаеш ш.,**
**Беренче май урамы, 39 нчы йорт,**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

---

**2024 елның 8 апреле** **30- РС номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 25 октябрендәге 77-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелек) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Лаеш муниципаль районы Советы карар кылды:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 25 октябрендәге 77-РС номерлы карары белән расланган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеген яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше буенча җитәкче урынбасарына йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**

*Лаеш муниципаль районы Советының 2024 елның __ __ номерлы карарына кушымта*

**Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

1. Контрольдәге зат тарафыннан җирле үзидарә органына реклама элмә тактасын килештерү турында гариза җибәрү факты булмаганда, автомобиль транспортын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәт күрсәтү буенча контрольдә тотылучының эшчәнлеге башланган көннән алып 90 календарь көн узу.

2. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, объектларны һәм төзекләндерү элементларын җыештыру буенча эшләрне башкару өчен билгеләнгән җыештыру һәм махсус техника санын арттырмыйча, шул ук вакыт аралыгында квартал өчен, әлеге эшләрне башкару бурычы йөкләнгән оешма хезмәткәрләре санының 50 һәм аннан да күбрәк процентка кимүе (ләкин кимендә ике хезмәткәргә).

3. Объектларны һәм төзекләндерү элементларын җыештыру эшләрен башкаруны үз бурычларына керткән оешманың хезмәт күрсәтү территориясендә, травма алуга бәйле рәвештә, травматологик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән гражданнар санының, алдагы вакытның шул ук чоры белән чагыштырганда, ике календарь атна эчендә, 15 һәм аннан да күбрәк процентка артуы.

4. Массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән һәм (яисә) кергән белешмәләрнең дөреслеген бәяләүгә юнәлдерелгән чаралар уздыру нәтиҗәсендә алынган төзекләндерү өлкәсендәге мәҗбүри таләпләрне бозуның булганлыгын һәм гражданнардан, оешмалардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан килгән кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү ихтималын таныклый торган Муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрендә билгеләнгән 30 календарь көн эчендә контроль объектының торышы тайпылуның өч һәм аннан да күбрәк шундый очраклар ачыклануы турында мәгълүмат булу.

5.Контрольдәге затка карата чыгарылган төзекләндерү өлкәсендәге мәҗбүри таләпләрне бозган өчен административ җәза билгеләү хакында административ хокук бозу турындагы эше буенча бер ел эчендә ким дигәндә биш карарның булуы.

6. Торак пунктның бер административ-территориаль берәмлеге (урам, микрорайон) территориясендә травма алуга бәйле рәвештә травматологик ярдәм күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән гражданнар санының, алдагы вакытның шул ук чоры белән чагыштырганда, ике календарь атна эчендә 15 һәм аннан да күбрәк процентка артуы».